**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге совхоз торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

14 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45, 69 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге совхоз торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең Воровский исемендәге совхоз торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә (1,2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, СВОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) «Воровский исемендәге совхоз торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Заречная ур., Новая ур.) (вак таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен килешү буенча түләү)».

3. Әлеге карарны Воровский авыл җирлеге мәгълүмат такталарында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Воровский исемендәге авыл
җирлеге башлыгы урынбасары В.П.Елхов